# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР
**дүртенче чакырылыш утыз икенче утырыш**

**Айдар авылы** **№ 95** **07.02.2024 ел**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2021 елның 11 май № 23 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Айдар авыл җирлеге Советының 2021 елның 11 май №23 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (18.08.2023 №81, 20.10.2023 № 86 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Күрсәтелгән карар белән расланган «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәнең 22 статьясындагы 3 пунктының, 25 статьясындагы 3 пунктының гамәлдә булуын 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Айдар авыл җирлеге башлыгы Х.Ш. Хәсәншин